**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23,
г.Лаишево
422610

Чернышевский урамы, 23 нче
йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

18 сентября 2023 №2921

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районы территориясендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны тану тәртибе турында Нигезләмәне раслау һәм комиссия төзү хакында» 2023 елның 15 июнендәге 1886 номерлы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә яшәүче (теркәлгән) гражданнарның торак шартларын яхшырту максатларында, аларны дәүләт (муниципаль) торак һәм башка программаларда катнаштыру максатларында, шул исәптән, инвалид булган гражданнарның торакка яисә җир кишәрлегенә хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, карар бирәм**:**

1. «Лаеш муниципаль районы территориясендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны тану тәртибе турында Нигезләмәне раслау һәм комиссия төзү хакында» 2023 елның 15 июнендәге 1886 номерлы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.О. Солягинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның«______» _ номерлы карарына кушымта.

Лаеш муниципаль районы территориясендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны тану тәртибе турында Нигезләмәне раслау һәм комиссия төзү хакында» 2023 елның 15 июнендәге 1886 номерлы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1) **5 статьяның 5.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
2) Гаризаны карау өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

- гаилә әгъзаларының паспортлары күчермәләре (барлык битләр);
- балалар туу турында таныклыкларның күчермәләрен;
- туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документларның күчермәләре (никах турында таныклык, никахны өзү турында таныклык, үлем турында таныклык (тулы булмаган гаиләгә кагылмый));
- адрес белешмәсе;
- гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының торак бинадан файдалану хокукын раслаучы документлар күчермәләре: торак бина бирү турында карар, ордер яки килешү, торак бинага милек хокукы турында таныклык һ. б.;
- гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары теркәлгән урын буенча торак бинаның гомуми мәйданын раслаучы документлар (техник паспорт, БТИ белешмәсе) агымдагы көнгә;
- - мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаилә әгъзаларын хосусыйлаштыруда катнашу турында 2000 елның1 гыйнварындагы Татарстан Республикасы территориясе буенча БТИ белешмәсе;
- хроник авыруның авыр формасы турында медицина нәтиҗәсе (кирәк булганда);
- торак урыннары өчен билгеләнгән таләпләргә (кирәк булганда) туры килмәвен раслаучы документ;

инвалидлык булуын раслаучы документ (кирәк булганда).